СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 сентября 2019 г. г.Мензелинск № 1

08.02.2019 елдагы «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы территориясендә уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүенә бәя бирү буенча иҗтимагый тикшерүне оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында"гы №6 Совет карарына үзгәрешләр кертү турында

1995 елның 23 ноябрендәге "Экологик экспертиза турында"гы №174-ФЗ, 2002 елның 10 гыйнварындагы "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында"гы №7-ФЗ, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ Федераль законнарын кулланып, Россия Дәүләт экология комитетының 2000 елның 16 маендагы "Россия Федерациясендә удыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүенә бәя бирү турында Нигезләмәне раслау турында"гы №372 боерыгы нигезендә Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Советның 08.02.2019 елдагы «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы территориясендә уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүенә бәя бирү буенча иҗтимагый тикшерүне оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында"гы №6 Совет карарын "Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру этаплары" 4 нче пункты һәм "Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирү процессында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү һәм катнашу" 5 нче пункты белән тулыландырырга.

2. Гамәлдәге карар Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Уставының 72 маддәсе нигезендә рәсми төстә басылып чыгарга тиеш.

3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл хуҗалыгы, экология һәм табигатьтән файдалану даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе А.Ф. Сәлахов

Минзәлә муниципаль район
Советы карарына
Кушымта
дата _________________ ел № ______

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы территориясендә уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүенә бәя бирү буенча иҗтимагый тикшерүне оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Гамәлдәге Нигезләмә экологик экспертиза объекты булган уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек, аның әйләнә-тирә мохитка мөмкин булган тәэсире турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү максатларында, тәэсир итүгә бәя бирү процессында аларны исәпкә алу һәм иҗтимагый өстенлекләрне ачыклау максатында, Минзәлә муниципаль районының җәмәгать тикшерүләрен әзерләү һәм уздыруны оештыру буенча мәсьәләләрне җайга сала.

1.2.Гамәлдәге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла: Уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка мөмкин булган тәэсиренә бәя бирүнең милли процедурасы – уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекне нигезләүче документациянең экологик экспертизасы һәм уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тәэсиренә бәя бирүне уздыру.

Билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тәэсиренә бәя бирү – мөмкин булган начар тәэсирне билгеләү, экологик нәтиҗәләргә бәя бирү, иҗтимагый фикерне исәпкә алу, тәэсирне киметү һәм булдырмау буенча чараларны эшкәртү юлы белән уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында экологик ориентлашкан идарәчелек карарын кабул итүгә булышучы процесс.

Экологик экспертиза – әлеге эшчәнлекнең әйләнә-тирә табигый мохитка мөмкин булган начар тәэсирен һәм аның белән бәйле социаль, икътисадый һәм экологик экспертиза объектны гамәлгә ашырганда башка нәтиҗәләрне кисәтү максатыннан, экологик экспертиза объектын гамәлгә ашыруның мөмкин булуын билгеләү һәм билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең таңгәллеген билгеләү.

Тәэсир итүгә бәя бирү буенча тикшеренүләр – тәэсир итүгә бәя бирү максатларын башкару өчен кирәкле мәгълүматны документацияләү, җыю һәм анализлау.

Билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек – әйләнә-тирә табигый мохитка тәэсир итәргә сәләтле һәм экологик экспертиза объекты булган эшчәнлек.

Заказ бирүче – әлеге төр эшчәнлеккә бирелгән норматив таләпләр

нигезендә уздыру билгеләнгән эшчәнлек буенча документация әзерләү өчен җавап бирүче һәм экологик экспертизага уздыру билгеләнгән эшчәнлек буенча документация тапшыручы юридик яисә физик зат.

Әйләнә-тирә мохиткa тәэсир итүгә бәя бирү буенча эшләрне башкаручы – заказ бирүче әйләнә-тирә мохиткa тәэсир итүгә бәя бирү буенча хокук биргән әйләнә-тирә мохиткa тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруны башкаручы (заказ бирүче яисә физик (юридик) зат физик яисә юридик зат.

Тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материаллар – уздыру билгеләнгән эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткa тәэсиренә бәя бирүне уздырганда әзерләнгән һәм экологик экспертизага тапшырылган документларның бер өлеше булган документация комплекты.

Иҗтимагый тикшерүләр – тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру барышында иҗтимагый өстенлекләрне ачыклау һәм аларны учетка алу максатыннан, уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткa мөмкин булган тәэсире турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирүгә юнәлтелгән гамәлдәге Нигезләмә һәм башка норматив документлар нигезендә тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру кысаларында уздырыла торган чаралар комплексы.

1.3.Әлеге эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткa тәэсирен һәм аның белән бәйле социаль, икътисадый һәм башка нәтиҗәләрне йомшарту яисә булдырмау әйләнә-тирә мохиткa тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруның максаты булып тора.

1.4.Нигезләүче документация 1995 елның 23 ноябрендәге “Экологик экспертиза турында”гы №174-ФЗ Федераль законы нигезендә экологик экспертиза уздырылырга тиеш булган уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлеге өчен әйләнә-тирә мохиткa тәэсиренә бәя бирү уздырыла. Эшләрнең тәртибе һәм эчтәлеге, әйләнә-тирә мохиткa тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча документация составы Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары, төрләр һәм билгеләнгән тәртиптә уздырылу билгеләнгән эшчәнлекнең конкрет характеристикасы нигезендә билгеләнә.

1.5. Әйләнә-тирә мохиткa тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларны әзерләүдә җәмәгатьчелекнең катнашуы түбәндәгечә башкарылырга мөмкин:

- беренчел мәгълүмат тапшырган этапта;

- әйләнә-тирә мохиткa тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру һәм нигезләүче документацияне әзерләү этабында.

1.6. Минзәлә муниципаль район территориясендә әйләнә-тирә мохиткa тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча иҗтимагый тикшерүләр предметы булыпдәүләт экологик экспертизасы объектының түбәндәге документациясе (алга таба – документлар) тора:

- уздыру билгеләнгән эшчәнлекнең гомуми тасвирламасын сыйдырган нигезләүче документация; аны гамәлгә ашыруның максатлары; мөмкин булган альтернативалар; аны гамәлгә ашыруның шартларын тасвирлау; гамәлдәге норматив документларда каралган башка мәгълүмат;

- алдан уздырылган әйләнә-тирә мохиткa тәэсир итүгә бәя бирү

нәтиҗәләре;

- әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруга техник бирем;

- дәүләт экологик экспертиза объектларына куела торган законда билгеләнгән таләпләргә тәңгәл килүче әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларның алдан эшләнгән варианты.

1.7. Иҗтимагый тикшерүләр түбәндәге формаларда уздырыла:

- иҗтимагый тыңлаулар;

- сораштыру;

- әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материаллар белән танышу, кимчелекләрне һәм тәкъдимнәрне бирү.

Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне халык белән турыдан-туры хәл иткән очракларда, Минзәлә муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә җирле референдум уздырыла.

1.8.Түбәндәге субъектларның (алга таба – инициаторлар) һич югында берсе уздыру зарурлыгы турында белдергән очракта, иҗтимагый тикшерүләр уздырыла:

- Минзәлә муниципаль район Советы;

- Минзәлә муниципаль район башлыгы – район Советы рәисе;

- Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет);

- заказ бирүче;

- экологик экспертиза таләп ителүче планлаштырылган, уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек белән мәнфәгатьләренә турыдан-туры яисә читтән кагыла торган юридик затлар һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләр;

- кимендә 10 кешедән торган, Минзәлә муниципаль район территориясе чикләрендә яшәүче һәм иҗтимагый фикер алышулар көненә 18 яшькә җиткән гражданнардан торган инициатив төркем;

- территориаль эшчәнлек өлкәсе Минзәлә муниципаль район территориясенә кагылган иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр.

1.9. Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирү нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

- билгеләнгән эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тәэсир итү масштабы һәм характеры, аны гамәлгә ашыруның альтернативалары, әлеге тәэсирнең экологик һәм аның белән бәйле социаль-икътисадый һәм башка нәтиҗәләрнең һәм аларның мөһимлегенең, тәэсир итүләрне минимальләштерү мөмкинлеге турында мәгълүмат;

- заказ бирүченең уздыру билгеләнгән эшчәнлеккә кагылышлы карар кабул иткәндә иҗтимагый өстенлекләрне ачыклау һәм учетка алу;

- уздыру билгеләнгән эшчәнлекне гамәлгә ашыруның альтернатив вариантларын билгеләү (шул исәптән объектның урнашу урыны турында, технологияләрне һәм башкаларны сайлау турында) яисә әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә уздырылган бәя бирү нәтиҗәләрен исәпкә алып, аны кире кагу

буенча заказ бирүченең карары.

Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру нәтиҗәләре экологик экспертизага бирелә торган бу эшчәнлек буенча документациянең бер өлеше булган, тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларда документлаштырыла.

## 2. Иҗтимагый тикшерүләрне оештыру һәм уздыру тәртибе

2.1. Башкарма комитет иҗтимагый тикшерүләр уздыруны оештыручы булып тора.

2.2. Инициатор Башкарма комитетка гариза, шулай ук иҗтимагый тикшерүләр уздыру буенча эш төркемен (алга таба – эш төркеме) кертү өчен инициатордан вәкилләр исемлеген тапшыра.

2.3. Заказ бирүче инициатор булган очракта, гаризага гамәлдәге нигезләмәнең 1.4 пунктында бәян ителгән документлар беркетелә.

2.4. Башкарма комитет инициатор булган очракта, гариза бирү таләп ителми.

2.5. Оештыручы:

- гаризаны тикшерә һәм Башкарма комитетта документ теркәлгәннән соң 5 эш көне эчендә заказ бирүче тапшырган документларның Россия Федерациясе кануннары таләпләренә туры килүен тикшерүне башкара;

- иҗтимагый тикшерүләрне оештырган очракта, инициатор белән берлектә уздыру датасын һәм вакытын билгели; бина бирүне оештыра һәм материалларны яздыру һәм кабаттан тыңлау, заказчы биргән кирәкле мәгълүмати материалларны демонстрацияләү өчен аудио- һәм видеоаппаратураны иҗтимагый тикшерүләр барышында файдалану мөмкинлеген тәэмин итә;

- гамәлдәге Нигезләмәнең 2.7 пункты нигезендә Башкарма комитет карары проектын әзерли;

- тикшерү өчен чыгарылаторган мәсьәләләр буенча махсус белемгә ия булган затларның (алга таба – экспертлар) исемлеген билгели; иҗтимагый тикшерүләр уздырылганчы алардан рекомендацияләр һәм тәкъдимнәр бирүләрен үтенеп, аларга чакыру кәгазе һәм мөрәҗәгатьләр җибәрә;

- җәмәгатьчелек вәкилләренең документларны карау мөмкинлеген тәэмин итә; - хәбәр язуы басылганнан, заказчыга кимчелекләр кертелгән вакыттан соң 30 календарь көн эчендә җәмәгатьчеле вәкилләреннән килгән тәкъдимнәрне һәм кимчелекләрне документлаштыруны һәм кабул итүне тәэмин итә;

- гамәлдәге Нигезләмәнең 2.10 пункты нигезендә иҗтимагый тикшерүләр уздыруны оештыра.

2.6. Заказ бирүче территорияләрендә, шулай ук территорияләрендә алар уздырылу алдыннан 30 календарь көннән дә ким булмаган вакытта уздырылу билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең дәүләт экология экспертизасы объектларын гамәлгә ашыру билгеләнгән Минзәлә муниципаль

районының җирле үзидарә органнарының һәм Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнарының рәсми басмаларында, башкарма хакимиятнең федераль органнарының рәсми басмаларында (федераль дәрәҗәдәге экспертиза объектлары өчен) иҗтимагый тикшерүләр уздыру турында хәбәр бастырып чыгаруны тәэмин итә.

Публикациядә түбәндәгеләр турында мәгълүмат тапшырыла:

- уздыру билгеләнгән эшчәнлекнең атамасы, максатлары һәм урнашу урыны турында;
- заказ бирүченең яисә аның вәкиленең атамасы, адресы, телефоны;
- әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруның чама белән сроклары;
- заказ бирүченең атамасы, адресы, телефоны;
- иҗтимагый тикшерү формасы, шулай ук кимчелекләр һәм тәкъдимнәр тапшыру формасы;
- әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча документларга керү сроклары һәм урыны;
- башка мәгълүмат;

2.6.1. Оештыручыга публикацияләр күчермәсен җибәрә.

2.6.2. Эшче төркем эшендә катнашуны тәэмин итә.

2.7. Иҗтимагый тикшерү уздыру турында карар Башкарма комитетның карары формасында кабул ителә, алар белән түбәндәгеләр билгеләнә:

- иҗтимагый тикшерүләр оештыру өчен нигезләмә;
- эшче төркем составы (эш төркеме рәисе, сәркатип һәм эш төркеме әгъзалары. Гомуми саны 7 кешедән ким түгел);
- гамәлдәге Нигезләмәнең 1.5 пункты нигезендә иҗтимагый тикшерүләр формасы;
-иҗтимагый тикшерүләр уздырылган очракта, - уздыру датасы, вакыты, урыны һәм тәртибе;
- тәкъдимнәр, рекомендацияләр һәм кимчелекләр бирү сроклары һәм урыны.

Башкарма комитет карары кул куелган көннән соң 10календарь көн эчендә гаммәви мәгълүмат чараларында басылып чыгарга тиеш.

2.8. Эшче төркем рәис, сәркатип, инициатор, оештыручы, экспертлар һәм комиссиянең башка әгъзаларыннан тора.

2.9. Эшче төркем:

- иҗтимагый тикшерүләрнең көн тәртибен әзерли;
- иҗтимагый тикшерүләрнең нәтиҗәләрен билгели.

2.10.Иҗтимагый тикшерүләр уздыру тәртибе:

2.10.1. Алып баручы (яисә эшче төркем рәисе):

- иҗтимагый тикшерүләрне ача;
- эшче төркем әгъзаларын игълан итә;
- иҗтимагый тикшерүләрнең уздыру тәртибен һәм тикшерүдә катнашучыларның чыгыш ясау вакыты турында игълан итә.

2.10.2. Заказ бирүче һәм аның вәкиле дәүләт экологик экспертизасы объекты турында кыскача доклад ясый.

2.10.3. Оештыручы кызыксынган җәмәгатьчелек вәкилләреннән кергән кимчелекләрне һәм тәкъдимнәрне укый.

2.10.4. Экспертлар, катнашучылар тема буенча кимчелекләр, тәкъдимнәр белән чыгыш ясыйлар, кергән сорауларга заказ бирүчедән җаваплар алалар.

Иҗтимагый тыңлауларда катнашучы чыгыш ясар алдыннан үз фамилиясен, исемен, атасының исемен, әгәр чыгыш ясаучы нинди дә булса оешманың вәкиле булып тора икән, вазыйфасын хәбәр итәргә тиеш.

2.10.5. Алып баручы (яисә эшче төркем рәисе) иҗтимагый тикшерүләрнең төп нәтиҗәләрен чыгара, иҗтимагый тикшерүләрнең беркетмәләрен әзерләү, аны имазалау, кимчелекләрне күрсәтү тәртибен аңлата.

2.10.6. Иҗтимагый тикшерүләрнең беркетмәсе эш төркеме сәркатибе тарафыннан алып барыла һәм тикшерүдә катнашучыларның чыгышларының эчтәлеген, сораулар һәм аларга җавапларны, тәкъдимнәр һәм кимчелекләрне, тавыш бирүдә кабул ителгән карарларны сыйдыра, объектка заказ бирүче, эш төркеменең рәисе һәм сәркатибе тарафыннан мәҗбүри төстә имзалана. Беркетмә иҗтимагый тикшерүләр уздырылган көннән соң 5 көн эчендә төзелә һәм Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

2.10.7.Уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында карар кабул ителгәнче чорда гражданнардан һәм иҗтимагый оешмалардан язмача кимчелекләрне һәм тәкъдимнәрне кабул итү, әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларга кушымталарда әлеге тәкъдимнәрне документлаштыру иҗтимагый тикшерүләр тәмамланганнан соң 30 көн эчендә заказ бирүче тарафыннан тәэмин ителә.

## 3. Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларга таләпләр

3.1. Уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүенә бәя бирүне уздыру буенча материаллар дәүләт экология экспертизасы тарафыннан кабул ителә торган әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыру мөмкинлеге турында карар әзерләү һәм кабул итүнең барлык стадияләрендә тапшырыла.

Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүенә бәя бирүне уздыру буенча материаллар әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүенә бәя бирүне уздыруның мөһим нәтиҗәләрен сыйдырган техник характерда булмаган резюмены үзенә кертергә тиеш.

3.2. Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүенә бәя бирүне уздыру буенча материаллар составы әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру тәртибе белән билгеләнә, экологик экспертиза объекты булган, әлеге эшчәнлекне нигезләүче документациягә таләпләрнең, уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең төренә бәйле.

Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүенә бәя бирүне уздыруның тулылыгы (детальләр белән) дәрәҗәсе уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең масштабына һәм төренә һәм аны гамәлгә ашыру төбәгенең үзенчәлекләренә бәйле.

Инвестицияле проектлауда уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүенә бәя бирүне уздыру буенча материалларның типовой эчтәлеге район Башкарма комитетының норматив-хокукый акты белән раслана.

3.3. Әгәр уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча документация керү чикләнгән мәгълүматка кертелгән булса, заказ бирүче әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларны мәгълүмати ачыклык принцибы нигезендә әзерли.

## 4. Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру этаплары

4.1. Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруга хәбәр җибәрү, алдан бәя бирү һәм техник задание төзү.

4.1.1. Беренче этап барышында заказ бирүче:

хакимият органнарына уздыру билгеләнгән эшчәнлекнең гомуми тасвирламасын сыйдырган нигезләүче документацияне; гамәлгә ашыруның максатларын; мөмкин булган альтернативаны; аны гамәлгә ашыруның шартларын тасвирлауны; гамәлдәге норматив документларда каралган башка мәгълүматны әзерли һәм тапшыра;

гамәлдәге Нигезләмә нигезендә җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирә; алдан бәя бирүне уздыра;

әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру процессында катнашучыларны, шул исәптән, кызыксынган җәмәгатьчелекне билгеләү максатыннан, алдан консультацияләр уздыра.

Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру барышында заказ бирүче түбәндәге мәгълүматны җыя һәм документлаштыра:

Уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында, аны гамәләгә ашыру максатын, мөмкин булган альтернативаларны, гамәлгә ашыру срокларын һәм мөмкин булган урнашу урынын, кагылучы административ территорияләрне, транс чикләргә тәэсир итү мөмкинлеген, территораль һәм тармак планнарына һәм программаларга тәңгәллеген кертеп;

тәэсир ителүгә дучар ителергә мөмкин булган әйләнә-тирә мохитның торышы, һәм аның аеруча зәгыйфь компонентлары турында;

әйләнә-тирә мохитка мөмкин булган әһәмиятле тәэсир итү (җир ресурсларына ихтыяҗ, калдыклар, транспорт һәм башка инфраструктураларга йөкләмәләр, чыгарма һәм ташлау чыганаклары) һәм әлеге тәэсирләрне киметү һәм булдырмау буенча чаралар турында.

4.1.2. Заказ бирүче тәэсир итүгә алдан бәя бирү нигезендә түбәндәгеләрне үз эченә алган әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруга техник бирем (алга таба – техник бирем) төзи:

заказ бирүченең (башкаручының) атамасы һәм адресы;

әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру сроклары;

әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруның төп ысуллары, шул исәптән, җәмәгатьчелек белән консультация уздыру планы; әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздырганда төп бурычлар;

әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча мөмкин булган состав һәм материаллар эчтәлеге.

ТБ төзегәндә заказ бирүче әйләнә-тирә мохитне саклау буенча махсус вәкаләтле органнарның таләпләрен, шулай ук әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру процессында башка катнашучыларның фикерен исәпкә ала. ТБ әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру процессында катнашучыларның запрослары буенча таратыла һәм әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруның бөтен вакыты дәвамында җәмәгатьчелек өчен ачык була.

Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруга ТБ Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларның бер өлеше булып тора.

4.2. Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруга тикшеренүләр уздыру һәм әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларның вариантын алдан әзерләү.

4.2.1. Заказ бирүче (башкаручы) гамәлгә ашыру альтернативаларын, эшчәнлек максатларын, аларга ирешү ысулларын исәпкә алып, ТБ нигезендә әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча тикшеренүләр уздыра һәм әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларның алдан әзерләнгән вариантын әзерли.

4.2.2. Уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча тикшеренүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә һәм мөмкин булган альтернативаларга характеристика билгеләү (шул исәптән, эшчәнлектән баш тарту);

уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең тәэсир итү мөмкинлеге булган территория торышына анализ (табигый мохитнең торышы, антропоген йөкләмә булу һәм аның характеры һ.б.лар);

альтернативаларны исәпкә алып, уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең тәэсир итү мөмкинлеген ачыклау;

уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру (куркыныч туу мөмкинлеге, дәрәҗәсе, характеры, масштабы, таралу зонасы, шулай ук экологик һәм аның белән бәйле социаль һәм икътисадый нәтиҗәләрне фаразлау);

негатив тәэсирләрне киметүче, йомшартучы яисә булдырмаучы чараларны билгеләү, аларның нәтиҗәлелеген һәм гамәлгә ашыру мөмкинлеген бәяләү;

әйләнә-тирә мохитка калдык тәэсирләрнең һәм аларның нәтиҗәләренең мөһимлегенә бәя бирү;

карала торган альтернативаларның көтелгән экологик һәм аның белән бәйле социаль-икътисадый нәтиҗәләрен чагыштыру, шул исәптән, эшчәнлектән баш тарту, гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителгән вариантны нигезләү;

уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруның барлык этапларында экологик мониторинг һәм контроль программасы буенча тәкъдимнәрне эшкәртү;

уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруга проекттан соң анализ уздыру буенча рекомендацияләрне эшкәртү;

уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларның вариантын алдан әзерләү (белгечләр өчен кыскача эчтәлеген кертеп).

4.2.3. Заказ бирүче уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларның алдан әзерләнгән варианты белән җәмәгатьчелеккә танышу һәм гамәлдәге Нигезләмәнең 4 бүлеге нигезендә үз кимчелекләрен җиткерү мөмкинлеген бирә.

4.3. Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларның соңгы вариантын әзерләү.

4.3.1. Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларның соңгы варианты гамәлдәге Нигезләмәнең 4 пункты нигезендә тикшерү барышында әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру вакытында катнашучылардан кергән кимчелекләр, тәкъдимнәр һәм мәгълүматларны исәпкә алып, материалларның алдан әзерләнгән варианты нигезендә әзерләнә.

Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларның соңгы вариантына кергән кимчелекләр һәм тәкъдимнәрне исәпкә алу исәпкә алу турында мәгълүмат, шулай ук иҗтимагый тикшерүләрнең (әгәр дә алар уздырылган булса) беркетмәләре кертелергә тиеш.

4.3.2. Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларның соңгы варианты заказ бирүче тарафыннан раслана, нигезләүче документны әзерләгәндә куллану өчен тапшырыла һәм аның составында дәүләт экологик экспертизасына, шулай ук иҗтимагый экологик экспертизага (уздырылган очракта) тапшырыла.

4.3.3. Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларны әзерләүдә җәмәгатьчелекнең катнашуы түбәндәгечә башкарылырга мөмкин:

беренчел мәгълүмат тапшырылган этапта;

әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру һәм нигезләүче документны әзерләү этабында.

Заказ бирүче уздыру билгеләнгән күздә тотылган инвестицияле эшчәнлек өчен дәүләт экологик экспертизасына тапшырыла торган уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча документация әзерләүнең

барлык стадияләрендә әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруның югарыда санап кителгән этапларын уздыра.

Мөһим экологик нәтиҗәләре булмаган һәм Россия Федерациясе субъектлары дәрәҗәсенең дәүләт экологик экспертизасы объекты булган эшчәнлекнең аерым төрләре (категорияләре) өчен әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру процессы гадиләштерелергә мөмкин.

Бу очракта, Россия Дәүләт экология комитетының территориаль органнары гамәлдәге Нигезләмәнең пункты 3.1.2, 3.1.3, 3.2.2, 3.2.3 һәм 3.3.1 пунктларына гына үзгәрешләр кертеп, эшчәнлекнең әлеге төрләре өчен әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруны регламентлаучы тиешле норматив документларны эшкәртә.

## 5. Әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру процессында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү һәм катнашу

5.1. Җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү һәм катнашу гамәлдәге Нигезләмә һәм билгеләнгән тәртиптә башка норматив хокукый документлар нигезендә әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруның барлык этапларында башкарыла.

5.2. Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру материалларын әзерләүдә һәм тикшерүдә җәмәгатьчелекнең катнашуы заказ бирүче тарафыннан әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру процессының аерылгысыз өлеше буларак тәэмин ителә, Россия кануннары нигезендә һәм җирле үзидарә органнары яисә дәүләт хакимиятенең тиешле органнары тарафыннан закза бирүче ярдәме белән уздырыла.

5.3. Җәмәгатьчелеккә һәм әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруда башка катнашучыларга хәбәр итү, алдан бәя бирү һәм әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруга техник бирем төзү этабында мәгълүмат бирү заказ бирүче тарафыннан башкарыла. Кыскача мәгълүмат территорияләрендә дәүләт экология экспертизасы объектын гамәлгә ашыру билгеләнгән, шулай ук территорияләрендә уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек тәэсир итә торган җирле үзидарә органнарында һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының рәсми басмаларында, башкарма хакимиятнең федераль органнарының рәсми басмаларында (федераль дәрәҗәдәге экспертиза объектлары өчен) басыла.

Басмаларда түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

уздыру билгеләнгән эшчәнлекнең атамасы, максатлары һәм урнашу урыны турында;

заказ бирүченең яисә аның вәкиленең атамасы һәм адресы турында;

әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруның чама белән сроклары турында;

иҗтимагый тикшерүләрне оештыру өчен җаваплы орган турында;

иҗтимагый тикшерүләрнең мөмкин булган формасы (сораштыру, тыңлаулар, референдум һ. б.лар), шулай ук кимчелекләр һәм тәкъдимнәрне тапшыру формалары турында;

әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча техник биремнең сроклары һәм керү мөмкин булган урыннар турында;

башка мәгълүмат.

5.4. Әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру процессында катнашучыларга өстәмә мәгълүмат бирү 3.1.1. пунктта күрсәтелгәнчә, радио, телевидение, вакытлы матбугат, Интернет һәм мәгълүмат таратуны тәэмин итүче башка ысуллар белән мәгълүмат тарату аша башкарылырга мөмкин.

5.5. Заказ бирүче (башкаручы) 3.1.1 пункты нигезендә мәгълүмат басылганнан соң 30 көн эчендә җәмәгатьчелектән кимчелекләрне һәм документларны кабул итә һәм документлаштыра. Әлеге кимчелекләр һәм тәкъдимнәр әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча техник бирем төзегәндә исәпкә алына һәм әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларда чагылырга тиеш.

5.6. Заказ бирүче әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча техник биремгә керү мөмкинлеген тәэмин итә һәм әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүгә бәя бирү процессы расланган вакыттан алып тәмамланганчы, әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруда катнашучы кызыксынган җәмәгатьчелек һәм башка катнашучыларга керү мөмкинлеген тәэмин итә.

5.7. Әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру этабында уздыру билгеләнгән хуҗалык эшчәнлегенең иҗтимагый тикшерүләр барышы буенча чаралар планы, шул исәптән, әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру материаллары буенча әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүгә бәя бирүне уздыруның максатчан булуы (максатка туры килмәве) турында тәгаенләнә.

Иҗтимагый тикшерүләр, шул исәптән иҗтимагый тыңлаулар формасы турында карар кабул ителгәндә, уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең экологик куркыныч дәрәҗәсен, билгесезлек факторын, җәмәгатьчелекнең кызыксынучанлык дәрәҗәсен кулланып эш итәргә кирәк.

5.8.Әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру буенча материалларның алдан эшләнгән вариантының сроклары һәм керү урыны, иҗтимагый тыңлауларны, иҗтимагый катнашуның башка формаларының уздыру датасы һәм урыны 3.1.1. пунктында күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чараларында иҗтимагый тикшерүләр (иҗтимагый тыңлаулар) уздыру тәмамланганчы 30 көннән соңармыйча басыла.

Заказ бирүче шулай ук әлеге мәгълүматны билгеләнгән эшчәнлек гамәлгә ашырылган очракта мәнфәгатьләре турыдан-туры яисә читтән кагыла торган яисә күрсәтелгән гаммәви мәгълүмат чараларына керү мөмкинлеге булмаган әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүгә бәя бирүне уздыру процессына кызыксынуын белдергән җәмәгатьчелеккә хәбәр итә.

5.9..Иҗтимагый тыңлауларны уздыру тәртибе заказ бирүче (башкаручы) катнашында һәм кызыксынган җәмәгатьчелек ярдәмендә җирле үзидарә

органнары тарафынна билгеләнә. Җәмәгатьчелек катнашы буенча барлык карарлар документлар белән рәсмиләштерелә.
Заказ бирүче тикшерүнең төп мәсьәләләрен конкрет билгеләп, планлаштырылган эшчәнлек буенча беркетмә төзеп, шулай ук җәмәгатьчелек һәм заказ бирүче арасында килешмәүчәнлек предметына (әгәр андый хәл ачыкланган булса) иҗтимагый тыңлаулар уздыруны тәэмин итә. Беркетмә башкарма хакимият һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре, гражданнар, иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр), заказ бирүче тарафыннан имзалана.
Иҗтимагый тыңлаулар уздыру беркетмәсе уздырылу билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүенә бәя бирүне уздыру буенча материалларның соңгы вариантына кушымталарның берсе сыйфатында керә.
5.10.Әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүенә бәя бирүне уздыру буенча материалларның алдан әзерләнгән вариантын танышу һәм кимчелекләр белдерү өчен җәмәгатьчелеккә тапшыру 30 көн эчендә, әмма иҗтимагый тикшерүләр (иҗтимагый тыңлаулар уздыру) тәмамланганчы, 2 атнадан да соңармыйча башкарыла.
Уздыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында карар кабул ителгәнгә кадәр чорда гражданнардан һәм иҗтимагый оешмалардан язмача кимчелекләр һәм тәкъдимнәр кабул итү, әлеге тәкъдимнәрне әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүенә бәя бирүне уздыру буенча материалларга кушымталарда документлаштыру закза бирүче тарафыннан иҗтимагый тыңлаулар узганнан соң 30 көн эчендә тәэмин ителә.
5.11. Заказ бирүче уздыру билгеләнгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында карар кабул ителгәнче һәм соңгысы расланган вакыттан бөтен срок эчендә әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүенә бәя бирүне уздыру буенча материалларның соңгы вариантына җәмәгатьчелеккә керү мөмкинлеген тәэмин итә.